**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» нче июнь 2021ел** **№ 87**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә нәтиҗәле һәм тәртипкә салынган җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Мүлмә авыл җирлегенең 2021 елның 01 мартындагы гавами тыңлаулары нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2021 елның 28 нче июндэ 87 нче
номерлы карары белән расланды

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

2021 ел

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ ..................................................................................................................................5
I КИСӘК. ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ТӘРТИБЕ, ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ..................................................................................................................................6
I БҮЛЕК. Гомуми нигезләмәләр..............................................................................................................6
1 статья. Әлеге кисәктә кулланыла торган төп төшенчәләр...................................................6
2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең хокукый статусы һәм составы ..........8
3 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы..........................................................................................................8
4 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең үз көченә керүе ..........................9
5 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен бозу өчен җаваплылык ......................9
II БҮЛЕК. Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр..................................................................................................................9
6 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре ........9
7 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе ...............**Ошибка! Закладка не определена.**
8 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең элек барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәле ...........................................................................................10
9 статья. Территориаль зоналар.. .........................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
10 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары ................................................................................11
11 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең башка мәсьәләләренә карата җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең гамәле ..........................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмәләр .....................**Ошибка! Закладка не определена.**
12 статья. Төп нигезләмәләр ....................................................................................................14
13 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе...........................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
14 статья. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе...........................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
IV БҮЛЕК. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмәләр................**Ошибка! Закладка не определена.**7
15 статья. Төп нигезләмәләр ...........................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**7
V БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмәләр ...........................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**8
16 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышулар гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру буенча гомуми нигезләмәләр

………..............................**Ошибка! Закладка не определена.**8
17 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру үзенчәлекләре…………………………………………………….
…………...**Ошибка! Закладка не определена.**8
18 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами
тыңлаулар............................................................................………………….............................**Ошибка! Закладка не определена.**9
19 статья. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар.........................................................................................................................20
VI БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәләр.......................................................................................................................................20
20 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе.....................20
VII БҮЛЕК. Җирдән файдалануның һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмәләр.......................................................................................................................................24
21 статья. Территориаль зоналар чикләре турында мәгълүматны күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү
……………………………………………….........................................**Ошибка! Закладка не определена.**4
II КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАЛАРЫ..............................................**Ошибка! Закладка не определена.**6
VIII БҮЛЕК. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары.......................**Ошибка! Закладка не определена.**6
22 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар..
.....…………………**Ошибка! Закладка не определена.**6
23 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре ……………………………………………………………
**Ошибка! Закладка не определена.**7
24. статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, тарихи җирлекләр территорияләре чикләре, мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре ………………………………………………………………………….........................27
III КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ
.......................................................**Ошибка! Закладка не определена.**8
IX БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен, җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларын билгеләү, өлешендә Шәһәр төзелеше регламентлары
.........................................................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**8
25 статья. Шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зоналар
..........................**Ошибка! Закладка не определена.**8
26 статья. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган җир кишәрлекләре булган территориаль зоналар
...................................………………………………………..................45
27 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләре булган территориаль зоналар ...................................……………………………………………………………………….45
X БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр

....................................................................................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**5
28 статья. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар ………………………**Ошибка! Закладка не определена.**5
29 статья. Инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының линияле объектларының санитар аермалары .....…………………………………………………………………………………**Ошибка! Закладка не определена.**9
30 статья. Табигый факторлар йогынтысы буенча җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш файдалануны чикләү........................... ...……………………………………………………………50
31 статья. Мәдәни мирас объектларын саклау шартлары буенча җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләү ....………...............................................51
XI БҮЛЕК. Территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре һәм мондый объектларның халык өчен территориаль мөмкин булган максималь күләменең исәп-хисап күрсәткечләре........................................................................................................................... 52
32 статья. Төп нигезләмәләр ......……………………………………………………………………52
XII БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләрен тасвирлау…..................52
КУШЫМТАЛАР ........................................................................................................................70
1 кушымта. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Территориаль зоналар ............................71
2 кушымта. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре ......................................................................................72
3 кушымта. VII бүлеккә кушымта...........................................................................................73

# КЕРЕШ

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) –территориаль зоналар, шәһәр төзелеше регламентлары, аны куллану тәртибе һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе билгеләнә торган җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән раслана торган шәһәр төзелешен зоналаштыру документы.

Кагыйдәләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының түбәндәге норматив хокукый актлары таләпләрен исәпкә алып әзерләнде:

– Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 29.12.2004 ел №190-ФЗ;
– Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 ел № 136-ФЗ;
– Россия Федерациясе Урман кодексы 04.12.2006 ел № 200-ФЗ;
– Россия Федерациясе Су кодексы 03.06.2006 ел № 74-ФЗ;
– «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;
– «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2006 елның 09 июнендәге 363 номерлы РФ Хөкүмәте карары;
– «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Кагыйдәләрне әзерләгәндә шулай ук Биектау муниципаль районының һәм «Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары нигезләмәләре, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый һәм шәһәр төзелеше үсешенең төп юнәлешләрен билгели торган башка документлар исәпкә алына.

# I КИСӘК. ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ТӘРТИБЕ, ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

## I БҮЛЕК. Гомуми нигезләмәләр

### 1статья. Әлеге кисәктә кулланыла торган төп төшенчәләр

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан рөхсәт ителгән файдалану төре** – җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның мөмкин булган ысулы. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре рөхсәт ителгән файдалануның төп, шартлы рөхсәт ителгән, ярдәмче төрләрен үз эченә ала һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы раслаган классификатор нигезендә билгеләнә.

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** – җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре, алар белән бергә гамәлгә ашырыла торган рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләренә карата өстәмә буларак кына рөхсәт ителә.

**Шәһәр төзелешен зоналаштыру** – территориаль зоналарны билгеләү һәм шәһәр төзелеше регламентларын билгеләү максатларында муниципаль берәмлекләр территорияләрен зоналаштыру.

**Шәһәр төзелеше регламенты** –тиешле территориаль зона чикләре чикләрендә билгеләнә торган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре, шулай ук җир кишәрлекләре өстендә һәм җир өслегендә булган нәрсәләр, аларны төзү һәм капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләү процессында файдаланыла торган барлык төрләре, җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләү, шулай ук чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территорияләргә карата куллану, халык өчен тиешле территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның территориаль файдалана алуының максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.

**Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе** – Кагыйдәләр әзерләүне оештыру, аларга үзгәрешләр кертү, гавами тыңлаулар уздыру һәм Кагыйдәләрне әзерләү Комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә башка мәсьәләләрне хәл итү максатында законнар, муниципаль хокукый актлар нигезендә төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган.

**Кызыл линияләр** – гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен күрсәткән һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яисә бетерелергә тиешле линияләр.

**Линияле объектлар** – электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре (шул исәптән линия-кабель корылмалары), торба үткәргечләр, автомобиль юллары, тимер юл линияләре һәм башка шундый корылмалар.

**Төзелеш алып баруның максималь проценты -** төзелеш алып барылырга мөмкин булган җир кишәрлегенең суммар мәйданы, җир кишәрлегенең бөтен мәйданына (%) мөнәсәбәте.

**Җир кишәрлеге чигеннән бинаның, төзелешнең, корылмаларның минималь чигенеше** – җир кишәрлеге чиге белән бина, төзелеш яки корылма арасындагы ераклык.

**Капиталь төзелеш объектлары -** биналар, корылмалар, төзелешләре тәмамланмаган объектлар, җир кишәрлегенең капиталь булмаган төзелмәләреннән, корылмаларыннан һәм аерылгысыз яхшыртуларыннан тыш (ныгытма, өслек һәм башкалар).

**Капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар** – җир белән ныклы бәйләнеше булмаган һәм конструктив характеристикалары аларны күчереп йөртү һәм (яисә) демонтаж үткәрү һәм аннан соңгы җыелуны төзелешләрнең, корылмаларның (шул исәптән киоскларның, түбәләрнең һәм башка шундый корылмаларның) төп характеристикалары үзгәртелмичә һәм билгеләнүгә тулысынча зыян китермичә һәм аннан соңгы җыемнарны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган төзелмәләр, корылмалар

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләре** – әлеге эшчәнлек төрләрен һәм шәһәр төзелеше регламентлары составындагы объектларны тиешле территориаль зоналарга карата күчерү нәтиҗәсендә мөмкин булган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре,

**Индивидуаль торак төзелеше объекты** – гражданнар тарафыннан мондый бинада яшәү белән бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән бүлмәләрдән һәм ярдәмче куллану биналарыннан торган һәм күчемсез мөлкәтнең мөстәкыйль объектларына бүлү өчен билгеләнмәгән җир өсте катлары саны өчтән, биеклеге егерме метрдан артмаган аерым бина

**Җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре** – җир милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен, капиталь төзелеш объектларын арендалаучылар, аларның вәкаләтле затлары.

**Җир участокларының иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** –җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре, шул исәптән аларның мәйданы; биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны мөмкин булган урнаштыру урыннарын билгеләү максатларында җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр; биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик саны яисә иң чик биеклеге; тиешле территориаль зоналарга карата шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлеге чикләрендә төзүнең максималь проценты.

**Гавами сервитут** – Россия Федерациясе законы яисә башка норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты, җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән җир кишәрлегеннән үзенә карата билгеләнә торган җир кишәрлекләрен тартып алмыйча гына чикләнгән файдалану хокукы.

**Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар** –законнарда билгеләнгән очракларда җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен муниципаль берәмлек (җәмәгатьчелек) халкының хокукларын гамәлгә ашыру формасы.

**Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы таләпләре нигезендә бирелә торган, җир кишәрлегенә иясенә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру, шулай ук аларны капиталь ремонтлауга тиешле территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга хокук бирә торган документ.

**Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы таләпләре нигезендә җир кишәрлекләренә хокук ияләренә җир кишәрлегеннән, әлеге Кагыйдәләр белән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектыннан файдалану төрен сайлау хокукын бирә торган документ.

**Территориаль зоналар** – җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә алар өчен чикләр билгеләнгән һәм шәһәр төзелеше регламентлары куелган зоналар.

**Гомуми файдалану территорияләре** – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, узу юллары, яр буйлары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар).

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39

статьясында билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алу шарты белән, әлеге эшчәнлек төрләрен һәм шәһәр төзелеше регламентлары составындагы объектларны тиешле территориаль зоналарга карата күчерү нәтиҗәсендә мөмкин булган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре.

**2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең хокукый статусы һәм составы**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре җирле үзидарә органының норматив хокукый акты статусына ия.

2. Әлеге Кагыйдәләр түбәндәгеләр белән беррәттән кулланыла:

техник регламентлар (алар үз көченә кергәнче билгеләнгән тәртиптә - 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы «Техник җайга салу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына каршы килми торган өлешендә норматив техник документлар);

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары;

шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

«Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлары.

3.Әлеге Кагыйдәләр үз эченә ала:

Кереш;

I Кисәк. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану тәртибе, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе;

II Кисәк. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары;

III Кисәк. Шәһәр төзелеше регламентлары;

Кушымталар.

4. Әлеге Кагыйдәләр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелешен көйләүче яисә контрольдә тотучы вазыйфаи затлар тарафыннан дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

**3статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы**

1. Әлеге Кагыйдәләр, аларның составына керүче барлык картографик һәм башка документларны да кертеп, барлык физик һәм юридик, шулай ук вазыйфаи затлар, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарына һәркем файдалана алырлык була.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары әлеге Кагыйдәләр белән танышу мөмкинлеген түбәндәге юллар белән тәэмин итәләр:

әлеге Кагыйдәләрне җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү), башка рәсми мәгълүмат өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару (халыкка җиткерү), һәм муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләрендә катнашучы органнарда һәм оешмаларда әлеге Кагыйдәләр белән тулы комплектта танышу өчен мөмкинлекләр тудыру;

территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында Кагыйдәләрне урнаштыру;

физик һәм юридик затларга әлеге Кагыйдәләрдән өземтәләр, шулай ук картографик материалларның кирәкле күчермәләрен һәм җирдән файдалану һәм төзелеш шартларын аерым җир

кишәрлекләренә һәм планировка структурасы элементларына карата характерлаучы аларның фрагментларын бирү. Әлеге материаллар югарыда күрсәтелгән затларга язма сорату буенча бирелә.

### 4статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең үз көченә керүе

1. Әлеге Кагыйдәләр җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.
2. Кагыйдәләр зуррак юридик көчкә ия булган хокукый актларга каршы килми торган өлештә эшли.

### 5 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен бозу өчен җаваплылык

1. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен физик һәм юридик затлар, шулай ук вазыйфаи затлар Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

## II БҮЛЕК. Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр

### 6 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә билгеләнә.
2. Биектау муниципаль районының җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы (алга таба - муниципаль район Советы) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:
Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен, шул исәптән Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр (өстәмәләр) раслау;
муниципаль районның шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау;
- гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләр.
3. Биектау муниципаль районының җирле үзидарәсе башкарма органының (алга таба - муниципаль район Башкарма комитеты) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:
төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш);
муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда хәбәрнамәләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш) җибәрү;
территорияне планлаштыру документларын раслау (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда);
муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару;
муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм тартып алу;
үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында я үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларына гражданнар законнарында каралган очракларда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары

параметрларына карата Кагыйдәләрдә, территорияне планлаштыру документларында, яисә мәҗбүри таләпләренә туры китерү турында карар кабул итү;

җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

Әлеге Кагыйдәләр нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты вәкаләтләренә шулай ук карыйлар:

җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү;

рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә башкарма органының (алга таба - җирлек Башкарма комитеты) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә вәкаләтләренә керә:

территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш).

**7 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе**

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) Кагыйдәләр проектын әзерләүне оештыру, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты Җитәкчесе карары нигезендә Кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатында төзелә.

2. Комиссия үз эшчәнлеген әлеге Кагыйдәләр, Комиссия турындагы Нигезләмә, җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертүне әзерләүне оештыру;

Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү мәсьәләләре буенча гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү;

гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү, тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесенә җибәрү;

Комиссия турында нигезләмә белән аңа йөкләнгән башка вәкаләтләр.

4. Комиссия карарлары беркетмәгә имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен тәкъдимнәр була.

5. Комиссия эше турында мәгълүмат барлык кызыксынучы затлар өчен ачык булып тора.

**8 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең элек барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәле**

1. Әлеге Кагыйдәләрне раслаганчы кабул ителгән җирле үзидарә органнарының җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлары әлеге Кагыйдәләргә каршы килми торган өлештә кулланыла.

2. Җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты әлеге Кагыйдәләргә туры килми, әгәр:

аларның рөхсәт ителгән файдалану төрләре тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төрләре исемлегенә кермәсә;

аларның күләмнәре һәм параметрлары тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән иң чик күрсәткечләргә туры килмәсә.

3. Шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләре яисә капиталь төзелеш объектлары, рөхсәт ителгән файдалану төрләре, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары аларны шәһәр төзелеше регламентына туры китерү срогын

билгеләмичә генә файдаланылырга мөмкин, моңа мондый җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану кеше тормышы яисә сәламәтлеге өчен куркыныч, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч булган очраклар керми.

4. Җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан, рөхсәт ителгән файдалану төрләреннән файдалану, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган очракта, кеше гомере яисә сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч һәм куркыныч янаган очракта, федераль законнар нигезендә мондый җир участокларын һәм объектларны куллануны тыю салынырга мөмкин.

5. Рөхсәт ителгән файдалану төрләре яисә чикле параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, мондый объектларны тиешле территория зонасының шәһәр төзелеше регламентына туры китерү юлы белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

**9 статья. Территориаль зоналар**

1. Территориаль зоналар түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

җир кишәрлекләреннән гамәлдәге һәм планлаштырыла торган файдалануның төрле төрләренең бер территориаль зонасы чикләрендә яраштыру мөмкинлекләрен;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы белән билгеләнгән функциональ зоналарын һәм аларның планлаштырыла торган үсеш параметрларын;

барлыкка килгән территорияне планлаштыру һәм гамәлдәге җирдән файдалануны;

төрле категориядәге җирләрнең чикләренең планлаштырылган үзгәрешләрен;

аралаш җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларына зыян китерү мөмкинлеген булдырмауны;

мәдәни мирас объектларын саклау зоналары проектларын.

2. Территориаль зоналарның чикләре түбәндәгеләр буйлап билгеләнә:

автомобиль юллары, урамнар, юл йөрү күчәрләре;

кызыл сызыклар;

җир кишәрлекләре чикләре;

табигать объектларының табигый чикләре;

торак пунктларның чикләре;

муниципаль берәмлек чикләре;

башка чикләр.

3. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында территориаль зоналарның чикләре билгеләнә. Территориаль зоналар чикләре һәр җир кишәрлегенең бары тик бер территориаль зонага гына туры килү таләбенә җавап бирергә тиеш, чикләре җир законнары нигезендә территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш.

**10 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары**

1. Шәһәр төзелеше регламентында шулай ук җир кишәрлекләре өслегендә булган һәм аларны төзү процессында һәм капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләү процессында кулланыла торган бөтен нәрсә кебек үк җир кишәрлекләренең хокукый режимы билгеләнә.

2. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

территориаль зона чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан фактта файдалануны;

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан гамәлдәге һәм планлаштырылган файдалануның төрле төрләренең бер территориаль зонасы чикләрендә яраштыру мөмкинлекләрен;

муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документларында билгеләнгән функциональ зоналарының һәм аларның планлаштырыла торган үсеш характеристикаларын;

мәдәни мирас объектларын, шулай ук аеруча саклanучы табигать территорияләрен, башка табигать объектларын саклау таләпләрен.

3. Шәһәр төзелеше регламентының гамәли көче тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан барлык җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына тигез дәрәҗәдә кагыла.

4. Шәһәр төзелеше регламенты түбәндәге җир кишәрлекләренә кагылмый:

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән ядкарьләр һәм ансамбльләр территорияләре чикләрендә, шулай ук мәдәни мирас объектлары ачыкланган ядкарьләр яисә ансамбльләр территорияләре чикләрендә һәм мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә торган реставрация, консервацияләү, торгызу, ремонтлау һәм җайлашу режимы турында карар кабул ителгән территорияләр чикләрендә;

гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрендә;

линияле объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм (яисә) линияле объектлар куелган;

файдалы казылмалар чыгару өчен бирелгән.

5. Тарихи җирлекләр территорияләренә, истәлекле урыннарга, дәвалау-савыктыру урыннары җирләренә һәм курортларга, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга карата шәһәр төзелеше регламентлары Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләр өчен билгеләнми:

урман фонды җирләре;

өслек сулары белән капланган җирләр;

запас җирләр;

махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары җирләреннән тыш);

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы авыл хуҗалыгы җирләре;

махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

7. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җир кишәрлекләреннән файдалану федераль законнар нигезендә вәкаләтле башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнә. Урман фонды җирләре составындагы җирләр яки җир кишәрлекләрен, махсус саклanучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдалану (махсус саклanучы табигать территорияләре составына кертелгән торак пунктлар территорияләреннән тыш) тиешенчә урман хуҗалыгы регламенты, урман законнары нигезендә махсус саклanучы табигать территориясе турындагы нигезләмә, махсус саклanучы табигать территорияләре турындагы законнар нигезендә билгеләнә.

8. Тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелә:

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары;

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чикләүләр;

территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм, шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган очракта, күрсәтелгән объектларның халык өчен территориаль файдалана алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.

**11 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең башка мәсьәләләренә карата Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең гамәле**

1. Әлеге бүлектә күрсәтелгән очраклардан тыш, территориаль зоналар һәм шәһәр төзелеше регламентлары чикләре турында белешмәләр кулланыла:

территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләгәндә (әлеге схема нигезендә төзелергә тиешле җир кишәрлекләренең һәркайсына карата әлеге схеманы раслау турындагы карарда шул исәптән җир кишәрлеге төзелә торган территория зонасы күрсәтелә, яисә шәһәр төзелеше регламентының төзелә торган җир кишәрлегенә кагылмаса яисә төзелә торган җир кишәрлеге өчен төзелә торган җир кишәрлегеннән файдалану төре билгеләнмәсә);

территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә (территорияне планлаштыру документларын әзерләү җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре билгеләгән территориаль зоналарга карата гамәлгә ашырылырга мөмкин);

җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләгәндә (җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы составында шул исәптән, җир кишәрлегенә шәһәр төзелеше регламенты гамәлдә булган очракта, шәһәр төзелеше регламенты турында мәгълүмат күрсәтелә).

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаган очракта, федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге объектларын, шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җир кишәрлекләрендә һәм федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, төзелешкә рөхсәтләр бирүгә юл куелмый.

3. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләргә карата Кагыйдәләр белән җир төзелеше эшләрен уздырганда җир кишәрлекләренә характеристика билгеләү максатыннан рөхсәт ителгән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре билгеләнә.

4. Җирле үзидарә органнары Кагыйдәләрне раслау турында яки Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта, әгәр мондый үзгәрешләр белән шәһәр төзелеше регламентын билгеләү яисә үзгәртү, территориаль зоналарның чикләрен билгеләү яисә үзгәртү каралган булса, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына белешмәләр кертү өчен документларны (аларда булган белешмәләрне) теркәү органына җибәрергә тиеш.

## III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затларның җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртүе турында нигезләмәләр

### 12 статья. Төп нигезләмәләр

1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Тиешле территориаль зонага билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм ярдәмче төрләре кулланылган шартта, рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

хокук иясе, рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында гариза, хокукны билгели торган документлар, шулай ук тиешле җир кишәрлеген аерым территориаль зонага (Кагыйдәләрдән өземтәгә) кертү турында муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән белешмә белән, әгәр тиешле территориаль зона турында белешмәләр күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булмаса, кадастр исәбе органына мөрәҗәгать итә;

хокук иясе җирле үзидарә органнарына мәгълүмат үзара хезмәттәшлеге тәртибендә җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты характеристикаларын үзгәртү турында белешмәләр җибәрү өчен рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

3. Тиешле территория зонасы өчен шартлыча рөхсәт ителгән башка төргә кагылышлы рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 13 статьясы нигезләмәләре нигезендә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Шәһәр төзелеше регламентлары гамәлдә булмаган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләрдә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү турындагы карарлар федераль законнар нигезендә мондый файдалануның башка төренә кабул ителә.

5. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегендә булмаган барлык башка төрләре әлеге территориаль зона өчен рөхсәт ителмәгән булып тора һәм әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр керткәндә генә рөхсәт ителергә мөмкин.

**13 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе**

1. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт бирелүдә кызыксынучы физик яисә юридик зат (алга таба - файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт) Комиссиягә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гариза җибәрә.

Куллануның шартлыча рөхсәт бирү турында гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

2. Куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм әлеге бүлекнең 18 статьясы нигезләмәләрендә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышуларда яисә гавами тыңлауларда каралырга тиеш.

3. Куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Комиссия, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр нигезендә муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесе мондый тәкъдимнәр кергән көннән алып өч көн эчендә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү яисә мондый рөхсәтне бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Күрсәтелгән карар муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга һәм муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында җирле үзидарә органына хәбәр кергән көннән башлап мондый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата яисә мондый төзелешне җимергәнче яисә билгеләнгән таләпләргә туры китергәнче, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүгә юл куелмый, әлеге хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт хакимиятенең башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм шушы хәбәрнамәне тапшырган җирле үзидарә органына үз белдеге белән төзелгән билгеләрнең булмавы йә иректе корылманы җимерү турындагы дәгъваларны канәгатьләндерүдән баш тарту яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы суд карары законлы көченә керүе хакында хәбәр җибәрелгән очраклардан тыш.

6. Физик яисә юридик зат файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

## *14*Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү тәртибе

1. Күләмнәре шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләренең минималь күләмнәреннән кимрәк яисә төзелеш алып бару өчен конфигурацияләре, инженерлык-геологик яисә башка характеристикалары уңайсыз булган булган җир кишәрлекләренең хокук ияләре рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.1. Җир кишәрлекләренең хокук ияләре мондый тайпылыш рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылу, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылыш конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын бер яисә берничә чик параметрга бер мәртәбә реконструкцияләү максатларында ун проценттан артмаган үзгәртү кирәк булганда.

2. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылу, техник регламентлар, норматив техник документлар таләпләрен үтәгәндә, аерым җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителә.

Катларның иң чик саны, биналарның, корылмаларның чик биеклеге һәм федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектур чишелешләренә таләпләр өлешендә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылу рөхсәт ителми.

3. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу белән кызыксынучы зат, Комиссиягә мондый рөхсәт бирү турында гариза җибәрә.

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

4. Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында карар проекты мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм, әлеге статьяның 1.1 өлешендә каралган очрактан тыш, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм әлеге бүлекнең 19 статьясы нигезләмәләрендә билгеләнгән тәртиптә җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиеш.

5. Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Комиссия, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәт бирү турында яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән рекомендацияләр нигезендә җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе мондый тәкъдимнәр кергән көннән җиде көн эчендә рөхсәт бирү турында, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

